**РАСЛЫЙМ**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, Мөфти
Камил хәзрәт Сәмигуллин
___________________

«19» октябрь 2017 ел

**РАСЛЫЙМ**
«Россия ислам институты» ректоры
Р.М. Мөхәммәтшин
___________________

«19» октябрь 2017 ел

**«Таян Аллага» әдәби конкурсының**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

**I. Конкурсның гомуми нигезләмәләре**

**1.1**. "Таян Аллага" әдәби конкурсы Россия Федерациясендә яшәүче татар яшьләре арасында яшь талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатында уздырыла.

Конкурсның бурычлары:

– сәләтле яшьләргә иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;
– татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм ислам динен пропагандалау.

Оештыручылар:

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Россия ислам институты.

**1.2.** Вакыты һәм үткәрү тәртибе

Конкурс өч этапта үтә:

1 этап — әсәрләрне җыю (1 ноябрь 2017 ел – 31 март 2018 ел)

2 этап — әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү (1 апрель – 31 май 2018 ел).

3 этап — нәтиҗәләрне игълан итү (июнь 2018 ел), җиңүчеләрне бүләкләү (сентябрь 2018 ел).

**II. Конкурста катнашу шартлары**

**2.1.** Конкурста Россия Федерациясендә яшәүче **10 яшьтән 35 яшькә кадәрле** һәрбер теләгән кеше катнаша ала.

**2.2.** Конкурс иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәүче яшьләр өчен үткәрелә, профессиональ язучыларның, шагыйрьләрнең, журналистларның әсәрләре һәм язмалары кабул ителми.

**2.3.** Конкурс дүрт номинациядә үтә:

– шигърият,
– чәчмә әсәрләр,
– драматургия,

– публицистик язмалар.

**2.4.** Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр һәм мәкаләләр **әдәби татар телендә** язылырга тиеш.

**2.5.** Аз күләмле әсәрләрне (шигырьләр, кыска хикәяләр h.б.) һәм публицистик язмаларны өчтән дә ким җибәрмәү сорала. Аларны түбәндәге таләпләргә туры китереп эшләргә кирәк: Times New Roman шрифтында, 14 нче кегль, бер ярым интервалда, сул яктан – 30 мм, уң яктан – 10 мм, өстән – 20 мм, астан – 20 мм.

**2.6.** Конкурска язмалар электрон вариантта кабул ителә. Конкурс материалларын җибәрү өчен электрон адрес: tatarkonkurs@mail.ru

**2.7.** Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында кыскача мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш. Конкурска җибәрелгән материаллар кабул ителгәннән соң, оештыру комитеты авторларның электрон почтасына раслау хаты җибәрә. Конкурс белән бәйле барлык мәгълүматлар да сайтка урнаштырылачак.

## III. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

3.1. Конкурста катнашучыларның әсәрләрен анализлау һәм бәяләү өчен оештыру комитеты тарафыннан махсус комиссия (жюри) билгеләнә.

3.2. Комиссия, конкурска килгән язмаларны тикшереп, һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны һәм гран-прига лаек әсәрне билгели. Моннан тыш, махсус бүләкләр булуы да мөмкин.

Жюри гран-при һәм призлы урыннарны бирмәү хокукына да ия.

Оештыру комитеты адресы: Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт. Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы. E-mail: tatarkonkurs@mail.ru

Белешмәләр өчен телефон: 8(843)2776826